СОВЕТ АЛЬДЕРМЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422711, Республика Татарстан, Высокогорский район, С. Альдермыш, ул. Хабибуллина, 2

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘЛДЕРМЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422711, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Әлдермеш авылы, Хабибуллин ур., 2

Тел./факс 8(84365) 79-4-03, e-mail:Alder Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**18 июль 2022 ел** **№ 55**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проектын гамәлдән чыгару хакында**

Федераль һәм региональ законнардагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 декабрендәге 173 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы проектын әзерләү максатларында (Советның 07.08.2020 № 139, 19.01.2021 N17 карарлары редакциясендә), әлеге үзгәрешләрне исәпкә алып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7, 20 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Әлдермеш авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Әлдермеш авыл җирлеге Советының 2021 елның 04 октябрендә 36 нчы номерлы « «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты хакында» карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Әлдермеш авыл җирлеге Советының 2021 елның 04 октябрендә 31 нченомерлы « «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты хакында» карары нигезендә 2021 елның 26 нчы октябрендә 10.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: РТ,Биектау районы, Әлдермеш авылы, Ленин ур., 26 й. үткәрелгән гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен гамәлдән чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 декабрендәге 173 номерлы карары белән кабул

ителгән ««Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» (Советның 07.08.2020 № 191, 19.01.2021 N17 карарлары редакциясендә) проектын, федераль һәм региональ законнардагы соңгы үзгәрешләрне исәпкә алып эшләргә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Н.Ә.Усманов